**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Дуртмунчинского сельского**
**поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Молодежная , д.148, с Дурт- Мунча,
Заинский район, (423515)
тел. 6-03-10

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Дурт- Мунча авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Яшьләр урамы, 148 нче йорт,
Дурт Мунча авылы Зәй районы
(423515) тел. 6-03-10

Телефон, факс 60 3 10. Электронный адрес: Durt.Zai@tatar.ru, сайт: www. durtmuncha.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
от 03.11.2020г. **№15**

**"Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2019 елның 17 маендагы 6 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2007 елның 29 июлендәге 324 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2019 елның 17 маендагы 6 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымтага үзгәреш кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 кушымта

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

1. Яшәү урыныннан, аннан алдагы яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

а) шәхесне таныклаучы документлар.

2. Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

а) шәхесне таныклаучы документлар;

б) соратып алына торган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар (паспорт, туу турында таныклык, никах теркәү таныклыгы).

3. Үлгән көнгә үлученең яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

а) шәхесне таныклаучы документлар;

б) үлем турында таныклык (оригинал);

в) соратып алына торган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар (балаларның туу турында таныклыклары, никах теркәү таныклыгы). ».

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т.Ситдиков**